| ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 21 октябре № 4

Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт авылында 2024 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2024 елның 1 ноябрендә 09.00 сәгатькә Түбән Бикмәт авылының ТР, Сарман муниципаль районы, Түбән Бикмәт авылы, Чапаев ур., 42а йорт адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык пункты бинасында Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүче:
1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә агачларны кисү (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын җыештыру (махсус техниканы арендалау, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү))

"ӘЙЕ " " ЮК?».

3. Әлеге карарны Кәүҗияк авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов